РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. А.Валеева, д. 50, Азнакаевский район,
с .Ильбяково, 423338,
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башкарма комитеты

Ә.Вәлиев ур., 50 йорт, Азнакай районы,
Илбәк авылы, 423338
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«13» ноябрь 2023 ел** **№ 6**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2023 елның 24 ноябрендә 10.00 сәгатьтә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Ә.Вәлиев урамы буенча 1 йорттан 61 йортка кадәр.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2023 елның 24 ноябрендә 13.00 сәгатьтә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә: Кооператив урамы буенча 1/1 йорттан 8/2 йортка кадәр, Профсоюз урамы буенча 5 йорттан 23 йортка кадәр.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыеның беренче этабын үткәрү вакыты – 2023 елның 24 ноябрендә 10.00 сәг тән 11.00 сәг кә кадәр;
- гражданнар җыеның беренче этабын үткәрү урыны – Илбәк авылы, балалар уен мәйданчыгы торриториясе;

- гражданнар җыеның икенче этабын үткәрү вакыты – 2023 елның 24 ноябрендә 13.00 сәг тән 14.00 сәг кә кадәр;

- гражданнар җыеның икенче этабын үткәрү урыны – Илбәк авылы, балалар уен мәйданчыгы торриториясе дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 14 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Илбәк авылы, Ә.Вәлиев ур, 10а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Илбәк торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән Илбәк торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда 1төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 250 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Илбәк авылында урамнарны яктыртуны оештыру (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Илбәк торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту; вак ташны сатып алу, ташу, Ә.Вәлиев, Профсоюзная урамнарына вак ташны җәю, эшкә килешү буенча түләү, тракторчыга хезмәт хакын түләү));
- традицион күмү урыннарын төзекләндерү (куакларны кисү, экскаватор белән агачларны төпләү, гербицид белән химик эшкәртү, эш өчен килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 10а йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Р.К.Галимҗанова